**Республика Татарстан**
**Зеленодольский**
**районы**
**муниципальный район**
**Исполнительный комитет**
**Большеякинского**
**сельского поселения**
**ул.Школьная, д.1, с.Большие Яки**
**Зеленодольский район**

**Татарстан Республикасы**
**Зеленодольск муниципаль**

**Олы Яке авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

**Мәктәп ур. Олы Яке ав.**
**Зеленодольск районы**

---

# КАРАР

**28 март 2019 ел** **№50**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196нчы "Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" карары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "2019 елда түләүләрнең, пособиеләрнең һәм компенсацияләрнең индексацияләү коэффицентын раслау турында"гы 2019 елның 24 гыйнварындагы 32нче номерлы карары нигезендә, Зеленодол муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегендә, 1нче, 2нче кушымталарга яраклы рәвештә, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокук мәгълумат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы (http//zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, шулай ук, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Олы Яке авылы, Мәктәп ур, 1а йорты (Олы Яке күп функцияле үзәк бинасы), Каратмән авылы, Клуб урамы, 23нче йорт (Каратмән авыл клубы бинасы), Уразлы авылы, Дуслык урамы, 3нче йорт (Уразлы авылы клубы бинасы) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның гамәлгә ашырылуын контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы: Ф.А.Фәйзуллина

Олы Җәке авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 28 мартындагы
50 нче номерлы карарына
1нче кушымта

**ТР Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек хезмәтләре бәясе**

| | Хезмәтләр исемлеге | Хезмәтләрнең бәясе (сум) |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны әзерләү | 87,88 |
| 2 | Җирләү өчен кирәк булган әйберләр белән тәэмин итү | 3240,53 |
| 3 | Мәетне зиратка транспорт белән алып бару | 923,12 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1694,94 |
| | **Барлыгы:** | **5946,47** |

Зеленодольск муниципаль районы
Олы Җәке авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 28 мартындагы
50 нче номерлы карарына
2нче кушымта

**ТР Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек хезмәтләре бәясе**

| | Хезмәтләр исемлеге | Хезмәтләрнең бәясе (сум) |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны әзерләү | 87,88 |
| 2 | Мәетне кәфенләү | 572,51 |
| 3 | Җирләү өчен кирәк булган әйберләр белән тәэмин итү | 2668,02 |
| 4 | Мәетне зиратка транспорт белән алып бару | 923,12 |
| 5 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1694,94 |
| | **Барлыгы:** | **5946,47** |